# Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Байморза торак пунктында
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» октябрь, 2019 № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Байморза торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда үзара салым акчаларын Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Байморза авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә алып барырга.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- агачлар кистерү;
- материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, сууткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:
- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:
- зиратларны тезекләндерү һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков